СОВЕТ НИЖНЕУСЛОНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Ул. Заводская, д.55, с. Нижний Услон, 422574

Завод ур., 55 нче йорт, Түбән Ослан авылы, 422574

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ

КАРАР

05.11.2025

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

2-15

с. Нижний Услон

Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең
торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнарның үзара салымын кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә, Түбән Ослан авылының бер өлешендә яшәүчеләр төркеме инициативасын карап,

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2025 елның 18 ноябренә Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнардан үзара салым акчасын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга;
«2025 елда Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең Воробьевка авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 42 943 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- Ленин урамы буенча торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Түбән Ослан авылы, Ленин урамындагы 47 нче йорт янында гражданнар җыенын 13.00 сәгатьтә үткәрергә.

4. Түбән Ослан авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы А.В. Архиреев